КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 сентябрь г.Казань № 871

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразларын эшләү, төзәтү, иҗтимагый тикшерү, мониторинглау һәм тормышка ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» 2015 ел, 16 май, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 август, 733 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразларын эшләү, төзәтү, иҗтимагый тикшерү, мониторинглау һәм тормышка ашыруны тикшерүдә тоту тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Фаразлар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән дәрәҗәсен бәяләүне;

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең эчке шартлары вариантларын һәм тасвирламаларын (демографик һәм фәнни-техник үсешнең,

әйләнә-тирә мохитнең һәм табигый ресурсларның төп күрсәткечләрен кертеп) билгеләүне;

Татарстан Республикасының икътисадый үсеше факторларын һәм чикләүләрен бәяләүне;

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше юнәлешләрен һәм фаразның бер яки берничә вариантының максатчан күрсәткечләрен (социаль-икътисадый үсешнең сан күрсәткечләрен һәм сыйфат тасвирламаларын кертеп);

Татарстан Республикасы дәүләт программаларының төп параметрларын;

икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча үсешнең төп күрсәткечләрен, Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән күздә тотылган чараларны үткәрүне исәпкә алып, транспорт һәм энергетика инфраструктураларын үстерү күрсәткечләрен;

Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын, шул исәптән икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләнгән башка нигезләмәләрне.»;

2.7 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«уртача вакытлы һәм озак вакытлы чорларга фаразларныраслый (хуплый) һәм аларны раслаган (хуплаган) көннән 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра;».

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин